ГЛАВА
БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422646, с. Большой Ошняк,
ул. Г.Тукая, дом 28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422646, Олы Әшнәк,
Г.Тукай урамы, 28а йорт

Тел.: (84361) 27-732, факс: (84361) 27-738, эл.адрес: Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

. 2019 елның 18 октябре Олы Әшнәк авылы № 3

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Әшнәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 30 октябрендә 9 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 30 октябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2019 елның 30 октябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2019 елның 30 октябрендә 15 сәг. 00 минутка билгеләргә
5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
6. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Әшнәк авылының Мәктәп урамында, Кече Әшнәк авылының Совет урамында юлны ремонтлауга;

- Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авылларында контейнер мәйданчыклары ясауга;

- кышын Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авылларында урамнарны карап торуга (кардан чистартуга);

- урам утларына электр энергиясен саклаучы лампалар сатып алуга;

- ветеринария чараларын уздыру өчен Кече Әшнәк авылында раскол (станок) ясау.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

7. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорты;Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

8. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы Р.А.Хөснетдинова